**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Иске Иркәнәш торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

№ 2 28 ноябрь 2025

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Иске Иркәнәш торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иркәнәш авыл җирлегенең Иске Иркәнәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучы гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, һәм СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, Иске Иркәнәш торак пунктында урам яктыртуын агымдагы ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, килешү буенча эшләр өчен түләү);
2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Иркенәш торак пунктында 1 Май һәм Тукай урамнары арасындагы юлны ремонтлау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Иркенәш торак пунктында су алу колонкасы өчен будка сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Иркенәш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Иркәнәш авыл җирлеге башлыгы И.З.Камалов